**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Урта Кумор авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь, 2020 ел** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегенең Түбән Кумор авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 25 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегенең Түбән Кумор авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Кумор авылы, Тау өсте урамы, 6б йорты адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк (МФЦ) бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 25 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегенең Түбән Кумор авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Кумор авылы, Тау өсте урамы, 6б йорты адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк (МФЦ) бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегенең Түбән Кумор авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Түбән Кумор авылы урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Түбән Кумор авылына тирәнлек насосы (глубинный насос) сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- һәйкәл төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Түбән Кумор авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- юл полотносын торгызу;
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Урта Кумор авылы җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Кумор авыл
җирлеге башлыгы: Ю.И.Исынбаев